МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.04.2020 г. Казань № 61-ОД

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына граждannardan һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ уздыру тәртибе турында

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ уздыруның кушымтада бирелгән тәртибен расларга.

2. Эш башкару һәм контрольлек бүлегенә (Л.В.Авдошина) яртыеллыкның соңгы аеннан соңгы айның 15 нче көненә кадәр – елга ике мәртәбә гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ (алга таба – анализ) үткәрергә.

3. Җыелма бүлеккә (Л.М.Кадыйрова) анализны яртыеллыкның соңгы аеннан соңгы айның 15 нче көненнән соңга калмыйча Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ уздыру тәртибен раслау турында» 2015 елның 14 июлендәге 212-ОД номерлы боерыгын гамәлдән чыккан дип танырга.

5. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны министр урынбасары А.Ш.Хөсәеновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр А.Ә.Кәримов

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2020 елның 13 апрелендәге 61-ОД номерлы боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ уздыру тәртибе**

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә әзерләнде һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына (алга таба – Министрлык) гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләрне (алга таба – мөрәҗәгатьләр) гомумиләштерү һәм аларга анализ уздыру процедурасын билгели.

2. Мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау Министрлыкның эш башкару һәм контрольлек бүлеге (алга таба – Бүлек) тарафыннан электрон документлар әйләнеше белешмәләре һәм әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә тапшырыла торган мәгълүмат нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры, министр урынбасарлары, эшләр белән идарә итүче (алга таба – Министрлык җитәкчелеге, гражданнарны кабул итүгә вәкаләтле затлар) тарафыннан шәхсән кабул итү, шулай ук урынга чыгып кабул итү барышында алынган мөрәҗәгатьләр турындагы мәгълүмат гражданнарны шәхсән кабул итүгә, шулай ук Министрлык җитәкчелеге тарафыннан урынга чыгып кабул итүгә теркәүне гамәлгә ашыручы белгеч тарафыннан Бүлеккә тапшырыла.

4. Анализ уздырганда килгән, башка адреска җибәрелгән һәм каралган мөрәҗәгатьләрнең, электрон документ формасындагы мөрәҗәгатьләрнең саны турында, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре турында, шәхсән кабул итү барышында кабул ителгән гражданнарның саны турында, гражданнарны шәхсән кабул итүгә һәм урынга чыгып шәхсән кабул итүгә вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында мәгълүмат, шулай ук кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар (булган очракта) турындагы мәгълүмат өйрәнелә.

5. Әлеге Тәртипнең 3 пуктында күрсәтелгән мәгълүмат агымдагы айның 20 нче көненә кадәр, ай саен җаваплы хезмәткәрләр тарафыннан Бүлеккә тапшырыла.

6. Бүлек башлыгы әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән һәм әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә килгән мәгълүматны ике эш көне эчендә гомумиләштерә һәм анализлый һәм Министрлыкның эшләр белән идарә итүчесе белән килештерә.

7. Мөрәҗәгатьләр анализы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыру өчен Җыелма бүлеккә җибәрелә. Анализ яртыеллыкның соңгы аеннан соңгы айның 15 нче көненнән соңга калмыйча Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

8. Министрлыкта гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ Министрлыкның рәсми сайтында (http://mpt.tatarstan.ru/) гомуми файдаланудагы ачык мәгълүмат булып тора.